ГЛАВА НИЖНЕТАКАНЫШСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
МАМАДЫШСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ул.Банковская, д.17, с. Нижний Таканыш,
Мамадышский район,
Республика Татарстан, 422140

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МАМАДЫШ МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОНЫ ТҮБӘН ТӘКӘНЕШ
АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ БАШЛЫГЫ
Банк ур., 17 нче йорт, Түбән Тәкәнеш авылы,
Мамадыш районы,
Татарстан Республикасы,422140

тел.(факс): (85563) 2-63-21; e-mail: Nakt.Mam@tatar.ru, www:mamadysh.tatarstan.ru

Карар
"23" октябрь 2020 ел.

Постановление
№ 4

Мамадыш муниципаль районы Түбән Тәкәнеш авыл җирлеге
Югары Тәкәнеш торак пунктында үзара салым акчаларын кертү һәм
алардан файдалану мәсьәләсе буенча узган гражданнар җыенында
катнашучы затларны теркәү турында

Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районының « Түбән Тәкәнеш авыл җирлеге" муниципаль берәмлеге Уставы, «Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Түбән Тәкәнеш авыл җирлеге составына керүче торак пунктларда гражданнар җыенын әзерләү һәм уздыру тәртибе турында" гы 2019 елның 14 октябрендәге 2-46 номерлы Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Түбән Тәкәнеш авыл җирлеге Советы карары белән расланган Нигезләмәнең 3.1 пункты нигезендә, КАРАР БИРӘМ:

1. Югары Тәкәнеш авыл клубы мөдире Файзуллина Гөлнур Камил кызын Мамадыш муниципаль районы Түбән Тәкәнеш авыл җирлегенең Югары Тәкәнеш торак пунктында 2020 елның 17 ноябрендә гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм алардан файдалану мәсьәләсе буенча гражданнар җыенында катнашучы сайлау хокукына ия булган затларны теркәү өчен җаваплы итеп билгеләргә.
2. Гражданнар җыенында катнашучы затларны Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Түбән Тәкәнеш авыл җирлеге Советы карары белән расланган Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Түбән Тәкәнеш авыл җирлеге составына керүче торак пунктларда гражданнар җыенын әзерләү һәм уздыру тәртибе турындагы Нигезләмә нигезендә теркәүне тәэмин итәргә.

3 Әлеге карарны авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында, Мамадыш муниципаль районының mamadysh.tatarstan.ru рәсми сайтында урнаштыру юлы белән игълан итәргә.

4. Әлеге карар аның басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Мамадыш муниципаль районы
Түбән Тәкәнеш авыл җирлеге башлыгы: Р.Җ.Һәмизуллин